СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

# КАРАРЫ
## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**2017 елның «27» июненнән** **№ 27-146**

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2005 елның 30 декабрендәге 5-37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013елның 25 июнендәге 50 – ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы кодексы һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2005 елның 30 декабрендәге 5-37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (1 нче кушымта):

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы структурасына баш белгеч штат берәмлеген кертергә;

1.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасыннан әйдәп баручы белгеч штат берәмлеген чыгарырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru электрон адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча комиссиясегә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2017 елның «27» июненнән
27-146 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы структурасы**

| **№ т/б** | **Вазифа атамасы** | **Берәмлекләр саны** |
|---|---|---|
| 1. | Рәис | 1 |
| 2. | Баш белгеч | 1 |
| 3. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |